ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.04.2022 г. Заинск № 196

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсе муниципаль маршруты буенча автомобиль транспортында көйләүле тарифлар буенча даими төстә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру белән бәйле эшләрне башкаручы юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр керми), шәхси эшмәкәрләргә чыгымнарын өлешчә кире кайтару максатында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июнендәге 391 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясы (1998 елның 31 июлендәге № 145-ФЗ), «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, "Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затлар - товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүчеләргә субсидияләр бирүне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрен тану турында" 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсе муниципаль маршруты буенча автомобиль транспортында көйләүле тарифлар буенча даими төстә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру белән бәйле эшләрне башкаручы юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр керми), шәхси эшмәкәрләргә чыгымнарын өлешчә кире кайтару максатында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июнендәге 391 номерлы карарына 1 нче кушымтада түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы пассажирлар йөртүче югалткан (керми калган) керемнәрне каплауга субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

**С = З – Д**

биредә:

С – субсидия күләме, мең сумнарда;

З – транспорт чарасының классына һәм маршрутның озынлыгына карап, 1 км юл йөрүнең иң чик норматив үзкыйммәтен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 гыйнварындагы 61 номерлы карары белән расланган җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга чыгымнар (1 километр өчен 20 утыру урынына кадәр, кече класс - 43 сум 05 тиен; 21-30 утыру урыны белән кече класс - 57,38 сум)

Д - даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүдән алынган керемнәр, мең сумнарда.

Пассажирлар йөртүченең керемнәре составында түбәндәге керем төрләре исәпкә алына:

- муниципаль район эчендә эш башкарган вакытта пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен бер тапкыр бирелә торган билетлар сатудан кергән табыш;
- социаль юл йөрү билетлары буенча гражданнарның ташламалы категорияләрен йөртүгә бәйле барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан бирелә торган чыгымнарны компенсацияләү суммасы.

Шул ук вакытта пассажирлар йөртүченең керемнәре транспорт чарасының пассажирлар белән тулылыгы күрсәткече 50% тан да ким булмаган күләмнән чыгып исәпләнә.»;

1.2. 5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5.1.1 пунктчасын өстәргә:

«5.1. Субсидия рәвешендә бирелә торган бюджет средстволарын алучы пассажирлар йөртү белән шөгыльләнүчеләр, тапшырылган документларны тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән керми калган керемнәр суммасының нигезсез булуы, шулай ук башка контроль чаралар үткәрү нәтиҗәсендә, фактта керми калган керемнәрне нигезсез арттыру ачыкланган очракта, акчаларны кире

кайтарырга бурычлы.

Зәй муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган алынмый калган керемнәрне компенсацияләү өчен түләүләр тиешле суммадан артып киткән очракта, субсидияне кире кайтару гамәлгә ашырыла.

5.1.1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органы субсидияләр бирә торган бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче) тарафыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, үтәлешен, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә муниципаль финанс тикшерүе органнары тарафыннан мәҗбүри тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыра.».

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсе муниципаль маршруты буенча автомобиль транспортында көйләүле тарифлар буенча даими төстә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру белән бәйле эшләрне башкаручы юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр керми), шәхси эшмәкәрләргә чыгымнарын өлешчә кире кайтару максатында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июнендәге 391 номерлы карарына 2 нче кушымтада түбәндәге үзгәрешне кертергә:

комиссия составына кертергә:

- Никифорова Гөлназ Хәмит кызын – Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Карар 2022 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.М. Хаҗиповка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

М.М. Хәбибуллин
885558 3-41-33

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 18.04
196 номерлы карарына
2 нче кушымта.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсен тәэмин итә торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортының җайга салына торган тарифлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү буенча комиссия**

**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Хаҗипов Р.М. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары - комиссия рәисе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Архипова Р.М. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә һәм эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары |
| Городнова О.В. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы |
| Лоптова Т.А. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе |
| Никифорова Г.Х. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы |
| Хәбибуллин М.М. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы». |